**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында, шулай ук кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә дәүләт идарәсен оештыру һәм координацияләү чаралары турында» 2007 елның 8 сентябрендәге ПУ-511 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-204 номерлы, 2009 елның 5 сентябрендәге ПУ-482 номерлы, 2011 елның 22 апрелендәге ПУ-235 номерлы, 2012 елның 11 июлендәге ПУ-457 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2013 елның 6 августындагы ПУ-716 номерлы, 2013 елның 9 октябрендәге ПУ-1007 номерлы, 2014 елның 22 февралендәге ПУ-198 номерлы, 2015 елның 19 мартындагы ПУ-298 номерлы, 2015 елның 14 ноябрендәге ПУ-1094 номерлы, 2016 елның 3 февралендәге ПУ-76 номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге ПУ-507 номерлы, 2018 елның 19 апрелендәге ПУ-325 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы һәм 2019 елның 11 апрелендәге ПУ-216 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.Г. Кантюковны, В.Ф. Михайловны, Ф.Ф. Мөхәммәтшинны, Р.А. Шәйхетдиновны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Аникин Анатолий Викентьевичны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсе административ органнар белән хезмәттәшлек секторы мөдирен;

Кәримуллин Таһир Вагыйзь улын – Татарстан Республикасы граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны;

Пуряев Айнур Солтангали улын – «Бөтенроссия фәнни-тикшеренү урманчылык һәм урман хуҗалыгын механикалаштыру институты» федераль бюджет учреждениесенең «Көнчыгыш Европа урман тәҗрибә станциясе» филиалы директорын, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе урынбасарын (килешү буенча);

Филиппов Артем Анатольевичны – «Урта Идел су хуҗалыгы» су хуҗалыгы буенча федераль дәүләт бюджет учреждениесе директоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны (килешү буенча);

Хәйруллин Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрын;

Хөсәенова Алинә Зөфәр кызын – Су ресурслары федераль агентлыгы Түбән Идел су бассейны идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге башлыгы урынбасарын (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

С.Д. Захаровның – «Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы (килешү буенча)»;

А.В. Молевның – «Татарстан Республикасы Граждан оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы баш белгече, Комиссия секретаре».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 10 сентябрь
№ ПУ-531